ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 360 от «20» 10 2020 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының 2016 елның
20 маендагы 534 нче карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49 һәм 50 статьялары, Россия Федерациясе Җинаять- башкарма кодексының 25 һәм 39 статьялары, «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 24 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Мамадыш район судының 2020 елның 06 июлендәге 2а-376/2020 нче эш буенча карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. “Мәҗбүри эшләр рәвешендәге җинаять җәзасы үтәүче объектлар төрләрен һәм исемлеген билгеләү турында” Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 20 маендагы 534 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри һәм төзәтү эшләре өчен урыннар (объектлар) исемлеген Россия суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Мамадыш районы филиалы белән килештереп, хөкем ителгәннәргә мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза бирү өчен урыннар (объектлар) исемлеген билгеләргә.

2. Әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән оешмалар һәм предприятиеләр җитәкчеләренә, Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 28, 43 статьясы нигезендә, инспекция белән килештереп, мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендәге җәзаны үтәү мәсьәләләре буенча җинаять-үтәтү инспекциясе белән хезмәттәшлек өчен җаваплы хезмәткәрләрне билгеләргә, билгеләнгән эшләрнең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә, инспекциягә законда билгеләнгән тәртиптә тотылган суммаларның хезмәт хакыннан тотып калынган төзәтү һәм мәҗбүри эшләр күләме турында хәбәр итәргә.

3. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә мәҗбүри төзәтү эшләрен башкару мәсьәләсе буенча авыл хуҗалыгы оешмалары белән үзара хезмәттәшлекне оештырырга тәкъдим итәргә.

0000010659

4. Инспекциягә затлар мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәгән оешмаларга хокукый һәм башка ярдәм күрсәтергә, шулай ук җәзаларны үтәүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплылыкны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары М.Р. Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче — И. М. Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының
20.10. 2020 ел, №360 карарына
кушымта

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә хөкем ителүчеләргә мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәтү урыннары (объектлар) исемлеге

1. "Стройсервис" АҖ
2. «Мамадышстрой» ЯАҖ
3. «Транспорт» ҖЧҖ
4. «Мелиорация» Мамадыш ПМК ААҖ
5. «Строитель» ҖЧҖ
6. Мамадыш муниципаль районының индивидуаль эшкуарлары
7. «Мамадыш ТКХ» ҖЧҖ
8. "СтройСити" ҖЧҖ
9. ««Мамадышские стальные профили»» ҖЧҖ
10. «Татаспиртпром» АҖ филиалы «Мамадыш спирт заводы»
11. «Мамадыш балык заводы» ҖЧҖ
12. «Мамадыш урман хуҗалыгы» ДБУ
13. «Мамадыш» ИК ҖЧҖ
14. "Шәһәр хуҗалыгы" МУП
15. «Омар агрофирмасы» ҖЧҖ
16. «Мамадыш сәнәгать комбинаты» ҖЧҖ
17. «Мамадыш базары» ҖЧҖ
18. «Азык-төлек программасы» АПК ҖЧҖ
19. Мамадыш муниципаль районының авыл хуҗалыгы оешмалары
20. Мамадыш муниципаль районының авыл җирлекләре башкарма комитетлары
21. Мамадыш муниципаль районының крестьян-фермер хуҗалыклары
22. «Мамадыш җылылык челтәрләре» ҖЧҖ
23. Мамадыш РУЭС-Таттелеком
24. «Татавтодор» ААҖ Мамадыш филиалы